**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 14 сентябрь № 642

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибен раслау турында» 2014 ел, 13 декабрь, 984 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибен раслау турында» 2014 ел, 13 декабрь, 984 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «178» саннарын «178.1» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.2 нче пунктта «178 статьясындагы 4.1 өлеше» сүзләрен «178.1 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Түбәндәге мәҗбүри квалификацион таләпләргә җавап бирә торган Россия Федерациясе гражданнары конкурста катнашырга хокуклы:

төзелеш, һәм (яки) юриспруденция, һәм (яки) икътисад белгечлеге буенча югары белеме һәм квалификациясе булган;

төзелеш өлкәсендә һәм (яки) торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кимендә 5 ел, шул исәптән җитәкче вазыйфасында кимендә 3 ел эш тәҗрибәсе булган;

Россия Федерациясе Конституциясен, Россия Федерациясе Граждан кодексын, Россия Федерациясе Торак кодексын, Россия Федерациясе Бюджет кодексын, Россия Федерациясе Салым кодексын, Россия Федерациясе Хезмәт кодексын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 ел, 25 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законны, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 ел, 21 декабрь, ФЗ-69 нчы Федераль законны, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне оештыруны һәм төбәк капиталь ремонт системалары эшләвен җайга сала торган Россия Федерациясе норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы һәм җирле үзидарә органнарын норматив хокукый актларын белгән;

компьютерның эчке һәм периферия җайланмалары белән эшләү; мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре белән эшләү; Microsoft Office белән эшләү; мәгълүмат-белешмә системалары («Гарант», «Консультант Плюс» һәм башкалар) белән эшләү; идарә карарларын оператив кабул итү һәм тормышка ашыру; бурычларның үтәлешен оештыру һәм тәэмин итү; эшлекле сөйләшүләр алып бару; халык алдында чыгыш ясау; дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары белән нәтиҗәле хезмәттәшлек итү эшен оештыру; квалификацияле һәм нәтиҗәле итеп эш планлаштыру; кабул ителә торган карарларның нәтиҗәләрен анализлау һәм фаразлау; шәхси конфликтларны булдырмау буенча квалификацияле эш күнекмәләре булган.

Конкурста катнашуга түбәндәге затлар кертелми:

суд тарафыннан хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган;

алкоголизм, наркомания, токсикомания, хроник һәм озакка сузылган психик авырулардан дәвалануга бәйле рәвештә наркология яки психоневрология диспансерында исәптә торган;

суд хөкеме гамәлдән чыгарылмаган яки тәмамланмаган булган;

эшчәнлек өлкәсенә бәйсез рәвештә административ хокук бозган өчен дисквалификацияләү формасында үтәлмәгән җәзасы булган.»;

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа тугызынчы – унберенче абзацлар өстәргә:

«конкурста катнашырга теләгән затның алкоголизм, наркомания, токсикомания, хроник һәм озакка сузылган психик авырулардан дәвалануга бәйле рәвештә исәптә тормавы турында наркология яки психоневрология диспансерыннан белешмә;

эчке эшләр органнарыннан хөкем ителгән булмау турында белешмә;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында соратыла торган зат турында мәгълүмат булмавы хакында салым органыннан белешмә;»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 3.20 нче пункт өстәргә:

«3.20. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, җирле үзидарә органы депутаты, дәүләт хезмәткәре булган конкурста җиңүче, конкурс комиссиясе тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән соң, бер ай эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, җирле үзидарә органы депутаты вәкаләтләрен туктатырга яки дәүләт хезмәте үтү турында хезмәт контрактын туктатырга һәм дәүләт хезмәтеннән китәргә тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков